**XVII ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 26**

Баек авылы 22 октябрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы « Баек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның «03» июлендәге 5 нче номерлы Баек авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, шулай ук блокланган торак төзелеше өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренең минималь күләмен 1 000 кв. м күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Совет рәисе, Баек авыл җирлеге башлыгы** **М.Ф. Фахерлегаянов**